**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Советы мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

---

**Арча шәһәр Советы**
# КАРАРЫ

**«03» август 2021 ел** **№ 40**

**«Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү Тәртибен раслау турында» Арча шәһәр Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 68 номерлы карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы вазифаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән артса.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе «Совет города Арск» И.Г. Нуриев